# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 6 статьяның икенче өлешендәге өченче абзацына «, беренче ярдәм күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяның өченче өлешенә «җирле үзидарә органнары тарафыннан» сүзләреннән соң «, шул исәптән торак пунктларның чикләреннән читтә,» сүзләрен өстәргә;

4) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив хокукый җайга салу**

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив хокукый җайга салу дәүләт хакимияте органнарының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә бәйле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар

кабул итүеннән гыйбарәт.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары үз компетенцияләре чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы таләпләренә каршы килми торган норматив хокукый актлар әзерләргә һәм расларга хокуклы.»;

5) 18 статьяның беренче өлешендә «, норматив документлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 19 статьяның җиденче өлешендәге җиденче абзацына «, беренче ярдәм күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

7) 22 статьяның икенче өлешендә «норматив документлар» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

8) 23 статьяның икенче өлешендә «федераль законнар һәм норматив документлар» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

9) 25 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорга тиешле территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы буенча Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар белән янгын куркынычсызлыгына өстәмә таләпләр, шул исәптән торак пунктларның чикләреннән читтә янгыннарны юк итүгә халыкны җәлеп итүне, гражданнарның урманнарга керүен тыюны, торак пунктларның чикләреннән читтә урман һәм башка янгыннарның торак пунктлар җирләренә таралуына каршы килә торган өстәмә чаралар (торак пунктларның чикләре буенча янгынга каршы казылган җирләрне арттыру, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру һәм шуңа охшаш башка чаралар) күрүне күздә тотучы таләпләр, билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 17-ТРЗ